ПРОЕКТ

Татарстан Республикасы
Арча район Советы тарафыннан
кертелә

**Татарстан Республикасы Арча районы Сарай-Чокырча тимер юл разъездын бетерү турында һәм «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

Татарстан Республикасы Арча районының Сарай-Чокырча тимер юл разъездын бетерергә.

**2 статья**

«Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (I өлеш); 2008, № 12 (VII өлеш); 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); 2013, № 7; 2014, № 12 (IV өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2026, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:


1) 3 статьяның унынчы абзацында «, Сарай-Чокырча тимер юл разъезды» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Арча муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү һәм
аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

«Арча муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге составына керүче
муниципаль берәмлекләрнең чикләре

## карта-схемасы




Шартлы билгеләр

- Татарстан Республикасы чиге
- муниципаль район чиге
12 - тоташу ноктасының тәртип саны
10 - жирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- жирлекнең административ үзәге

Муниципаль районның чиктәш
чикләре тасвирламасы

| | | |
|---|---|---|
| 1 – 1 | - | Марий Эл Республикасы |
| 13 (12) – 8 (13) | - | Марий Эл Республикасы |
| 8 (13) – 24 (50) | - | Балтач муниципаль районы |
| 24 (50) – 58 (49) | - | Саба муниципаль районы |
| 58 (49) – 66 (48) | - | Теләче муниципаль районы |
| 66 (48) – 64 (46) | - | Питрәч муниципаль районы |
| 64 (46) – 53 (47) | - | Биектау муниципаль районы |
| 53 (47) – 13 (12) | - | Әтнә муниципаль районы |

«Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемада № | Муниципаль берәмлекләр |
|---|---|
| 1 | Арча шәһәре |
| 2 | Апаз авыл җирлеге |
| 3 | Кәче авыл җирлеге |
| 4 | Наласа авыл җирлеге |
| 5 | Яңа Кенәр авыл җирлеге |
| 6 | Яңа Кишет авыл җирлеге |
| 7 | Яңа Кырлай авыл җирлеге |
| 8 | Сеҗе авыл җирлеге |
| 9 | Урта Аты авыл җирлеге |
| 10 | Урта Курса авыл җирлеге |
| 11 | Иске Кырлай авыл җирлеге |
| 12 | Иске Чүриле авыл җирлеге |
| 13 | Ташкичү авыл җирлеге |
| 14 | Үрнәк авыл җирлеге |
| 15 | Утар Аты авыл җирлеге |
| 16 | Шушмабаш авыл җирлеге |
| 17 | Яңасала авыл җирлеге |

».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

**«Татарстан Республикасы Арча районы Сарай-Чокырча тимер юл разъездын бетерү турында һәм «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасы Арча районы Сарай-Чокырча тимер юл разъездын бетерү турында һәм «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектында Арча районының Сарай-Чокырча тимер юл разъезды торак пунктын бетерү карала.

Арча муниципаль районында барлык торак пунктларның яшәешенә һәм үсешенә анализ ясалды.

Анализ нәтиҗәләре буенча бер торак пункты – Арча муниципаль районының Урта Курса авыл җирлеге составындагы Сарай-Чокырча тимер юл разъезды яшәүдән туктаган диярлек.

Арча муниципаль районының Урта Курса авыл җирлеге составына 7 торак пункт керә: Урта Курса авылы, анда яшәүчеләр саны - 220 кеше, Түбән Курса-195 кеше, Югары Курса – 192 кеше, Алан – 124 кеше, Сарай-Чокырча – 246 кеше, Курайван – 66 кеше, Сарай-Чокырча тимер юл разъезды – 0 кеше.

Сарай-Чокырча тимер юл разъезы региональ әһәмияттәге “Сеҗе-Арча” юлыннан якынча 3500 м ераклыкта урнашкан (территориаль планлаштыру документларында һәм Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрында торак пункт чиге турында белешмәләр юк, хәзерге вакытта аларның төгәл урынын билгеләү мөмкин түгел). Географик атамаларның Дәүләт каталогы мәгълүматлары буенча Сарай-Чокырча тимер юл разъезды түбәндәге географик координаталарда урнашкан:: киңлек: 56°04.4', озынлык: 50°01.9'.

Кадастр карталары нигезендә Сарай-Чокырча тимер юл разъезды торак пункты урынында тимер юл урнашкан. Җир түбәндәге категорияләргә керә: сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшырулар, телевидение, информатика җирләре, космик эшчәнлекне тәэмин итү өчен җирләр, оборона, иминлек җирләре һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр. Әлеге территориядә торак пунктларның җирләре юк.

Торак пункт урынын карау нәтиҗәсендә төзелешләрнең булуы ачыкланмаган. Барысы да урман белән капланган. Тимер юлы һәм Чокырча тукталыш платформасы бар. Территориядә электр линияләре терәкләре, үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү, су агызу, газ белән тәэмин итү юк, Урта Курса авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге юллар категориясенә кертелгән Түбән Курса торак пунктына кадәр юл бар. Әлеге торак пункт территориясендә социаль объектлар, мәдәни мирас объектлары шулай ук юк.

2002-2006 елларга авыл администрациясе нигез салган 6 нчы хуҗалык кенәгәсенә ярашлы, 3 йорт хуҗалыгы алып бару турында язулар гамәлгә ашырылган.

Урта Курса авыл җирлегенең 2007 елдан бүгенге көнгә кадәр салынган хуҗалык кенәгәләрендә Сарай-Чокырча тимер юл разъезды буенча йорт хуҗалыклары алып бару турында яңа язмалар юк.

Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлеге мәгълүматлары буенча, торак пунктта теркәлгән кешеләр юк.

Югарыда әйтелгәннәрне исәпкә алып, Сарай-Чокырча тимер юл разъезды торак пункт билгеләрен югалткан, яшәеш һәм алга таба үсеш перспективалары юк.

Фикер алышу нәтиҗәләре буенча “Урта Курса авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге халкы торак пунктны бетерү инициативасын хуплады, законнарда каралган процедуралар үтәлде. Тиешле карарлар Арча муниципаль районы һәм Урта Курса авыл җирлеге вәкиллекле органнары тарафыннан кабул ителде.

Закон проектын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар китермәячәк.

**«Татарстан Республикасы Арча районы Сарай-Чокырча тимер юл разъездын бетерү турында һәм «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасы Арча районы Сарай-Чокырча тимер юл разъездын бетерү турында һәм «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәртүне яисә кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы Арча районы Сарай-Чокырча тимер юл разъездын бетерү турында һәм «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы Арча районы Сарай-Чокырча тимер юл разъездын бетерү турында һәм «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән түләнә торган өстәмә чыгымнарны таләп итми.